ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26.02.2024 ел Баулы шәһәре №34

Яшь гаиләләргә торак сатып алу өчен бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен, 2024 елның беренче кварталына Баулы муниципаль районы буенча торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативын билгеләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы “Татарстан Республикасы халкының торак-коммуналь хуҗалыгын сыйфатлы торак һәм хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү” дәүләт программасын раслау хакында”карарына ярашлы, “2024 елның беренче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативы һәм 2024 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак бинаның гомуми мәйданының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында” Россия Федерациясе төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгының 2023 елның 11 декабрендәге 888/пр номерлы боерыгына таянып, Баулы шәһәрендә һәм Баулы районында торак биналарның бер квадрат метры бәясенең уртача күрсәткечен билгеләү буенча, 2024 елның 26 гыйнварындагы 20 номерлы “Татарстан Республикасы бәяләүчеләр союзы” Коммерциячел булмаган партнерлыгының Эксперт-консультация Советының тикшеренүе нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Яшь гаиләләргә торак сатып алу өчен бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен, 2024 елның беренче кварталына Баулы муниципаль районы буенча торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативын 45 000 (кырык биш мең) сум күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат Рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы (http://www.bavly.tatarstan.ru) сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әле карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров